Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

карары

№ 4 07.10.2024

Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге
Татар Такталы торак пунктында 2025 елда үзара салым
кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРЫ:

1. 2025 елда Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Татар Такталы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Спас районы, Татар Такталы авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елның 24 нчы октябренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:
“Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 нче группа инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән сез килешәсезме?:

1) Татар Такталы торак пунктында Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Татар Такталы торак пункты территориясен төзекләндерү (грейдировка, юлларны кардан чистарту,уләннәрне чаптыру, агачларны кистерү (ягулык-майлау материаллары, МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));

3) Татар Такталы торак пунктында Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (ягулык

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аграмак авыл җирлегенең рәсми сайтында http:/ www. spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АГРАМАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ